АССОЦИАЦИЯ
«СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНЫХ
ОБРАЗОВАНИЙ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН»

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕКЛӘРЕ
СОВЕТЫ»
АССОЦИАЦИЯСЕ

РЕШЕНИЕ ПРЕЗИДИУМА **ПРЕЗИДИУМ КАРАРЫ**

от 12.03.2020 № ПР-163-4

г. Казань

Район үзәгенең авыл җирлеге хакимияте вәкаләтләрен муниципаль районның җирле администрациясенә йөкләү турында

«Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Советы» Ассоциациясенең башкарма сәркатип урынбасары – юридик идарә башлыгы С. Н. Столяров мәгълүматын тыңлаганнан һәм фикер алышканнан соң, «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Советы» Ассоциациясе Президиумы (алга таба – Совет) **карар итте**:

1. Башкарма сәркатип урынбасары – Советның юридик идарә башлыгы С.Н.Столяровның законнарда билгеләнгән тәртиптә район үзәгенең авыл җирлеге хакимияте вәкаләтләрен муниципаль районның җирле администрациясенә йөкләү турындагы мәгълүматны игътибарга алырга.

2. Муниципаль районнарның вәкиллекле органнарына һәм муниципаль районнарның административ үзәкләре булган җирлекләрнең вәкиллекле органнарына район үзәгенең авыл җирлеге хакимияте вәкаләтләрен муниципаль районның җирле администрациясенә йөкләү турында карарлар кабул итүнең максатка ярашлы булуы турындагы мәсьәләне өйрәнергә тәкъдим итәргә.

Рәис **Ә.С.Гобәйдуллин**